КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1368

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк геологик контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 940 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк геологик контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 940 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төбәк дәүләт геологик контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында»;

карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Төбәк дәүләт геологик контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне расларга».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк геологик контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 940 нчы карары белән расланган Төбәк дәүләт геологик контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 – 1.4, 1.6, 2.1, 2.2, 3.1, 3.3, 3.4, 3.6, 4.1 – 4.3, 4.7 пунктларда, V бүлекнең беренче һәм унынчы абзацларында тиешле килешләрдәге «төбәк геологик контроле (күзәтчелеге)» сүзләрен тиешле килешләрдәге «төбәк дәүләт геологик контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

II, IV, VII бүлекләрнең, әлеге Нигезләмәгә кушымтаның исемнәрендә тиешле килешләрдәге «төбәк геологик контроле (күзәтчелеге)» сүзләрен тиешле килешләрдәге «төбәк геологик контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

VI бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VI. Төбәк дәүләт геологик контроле (күзәтчелеге) өчен төп күрсәткечләр
һәм аларның максатчан мәгънәләре, индикатив күрсәткечләр

Төбәк геологик контроль (күзәтчелек) өчен контроль төренең төп күрсәткече һәм аның максатчан мәгънәсе – ел саен Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендәге гомумтаралган файдалы казылмаларны лицензиясез чыгару фактлары санын киметү: 2020 елда – 69 берәмлеккә, 2021 елда – 65 берәмлеккә, 2022 елда – 61 берәмлеккә, 2023 елда – 57 берәмлеккә кадәр.

Төбәк дәүләт геологик контролен (күзәтчелекне) гамәлгә ашыру нәтиҗәлелегенең һәм эффективлыгының индикатив күрсәткечләре:

1. Чираттагы елга, риск белән бәйле юнәлештәге алымны исәпкә алып, тикшерүләр планын формалаштыру – әйе;

2. Җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә ачыкланган бозулар арасыннан бетерелгән бозулар өлеше – 96 процент;

3. Хисап чорында план буенча үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

4. Хисап чорында планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

5. Хисап чорында контрольдә тотылучы объектның мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторларында расланган параметрларга туры килүен яки контрольдә тотылучы объектның мондый параметрлардан читкә китүен ачыклау нигезендә планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

7. Хисап чорында хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны;

8. Хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларының һәр төре буенча хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

9. Хисап чорында үзара дистанцион хезмәттәшлек итү чараларыннан файдаланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

9. Хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

10. Хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында игълан ителгән кисәтүләр саны;

11. Хисап чорында нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

12. Хисап чорында йомгаклары буенча административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

13. Хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

14. Хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

15. Хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән һәм прокуратура органнары тарафыннан килештерелмәгән гаризалар саны;

16. Хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы объектларның гомуми саны;

17. Хисап чоры ахырына исәпкә алынган, риск категорияләренә кертелгән контрольдә тотылучы объектларның риск категорияләрендәге һәрберсе буенча саны;

18. Хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

19. Хисап чорында исәпкә алынган һәм аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән контрольдә тотылучы затлар саны;

20. Хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

21. Хисап чорында Министрлык тарафыннан карап тикшерү срогы бозылган шикаятьләр саны;

22. Хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән, карап тикшерү йомгаклары буенча Министрлыкның карарын тулысынча йә өлешчә гамәлдән чыгару турында яисә Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләрен (гамәл кылмавын) гамәлдән чыккан дип тану турында карар кабул ителгән шикаятьләр саны;

23. Хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан Министрлыкның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән дәгъва гаризалары саны;

24. Хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан Министрлыкның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән, белдерелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны;

25. Хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) гамәлдән чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.».

3. Бу карар 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин